СОВЕТ САБИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
422060, Республика Татарстан, Сабинский район,
п.г.т. Богатые Сабы, ул. Г.Закирова, 52

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
САБА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ
422060, Татарстан Республикасы, Саба районы,
Байлар Сабасы ш.т.п., Г.Закиров урамы, 52 йорт

тел. (84362) 2-31-33, 2-31-44, факс (84362) 2-31-74, e-mail: saba@tatar.ru, www.saby.tatarstan.ru

№ 281 от 16.01.2019

на № _______ от _______________

# КАРАР

Җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясен раслау буенча вәкаләтләрне тапшыру турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясының 4 өлеше, «Җирләү һәм җирләү эше турында»гы 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында «Күмү һәм җирләү эше турында»гы Федераль законны гәмәлгә ашыру чаралары турында»гы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы составына керүче Арташ, Олы Кибәче, Олы Нырты, Олы Шыңар, Югары Симет, Явлаштау, Эзмә, Иштуган, Килдебәк, Курсабаш, Мишә, Мичән, Түбән Шытсу, Сатыш, Иске Икшермә, Тимершык, Шекше, Шәмәрдән, Юлбат авыл җирлекләре һәм «Байлар Сабасы ш.т.п.» муниципаль берәмлеге Советларына җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләренең бәясен раслау буенча җирлекләрнең башкарма комитетлары вәкаләтләрен Саба муниципаль районы Башкарма комитетына тапшырырга.

2. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы составына керүче Арташ, Олы Кибәче, Олы Нырты, Олы Шыңар, Югары Симет, Явлаштау, Эзмә, Иштуган, Килдебәк, Курсабаш, Мишә, Мичән, Түбән Шытсу, Сатыш, Иске Икшермә, Тимершык, Шекше, Шәмәрдән, Юлбат авыл җирлекләре һәм «Байлар Сабасы ш.т.п.» муниципаль берәмлеге Советлары тарафыннан әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән тәкъдим кабул ителгән очракта Саба муниципаль районы Башкарма комитетына:

– Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы авыл һәм шәһәр җирлекләренең башкарма комитетлары белән әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән вәкаләтләрне тапшыру турында килешүләр төзергә;

– әлеге карарны тормышка ашыруны тәэмин итү максатларында Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Советының 2018 нче елның 19 нчы декабрендә кабул ителгән 272 нче номерлы «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының 2019 нчы елга һәм 2020-2021 елларның план чорына бюджеты турында»гы карарына үзгәрешләр кертү турында карары проектын бюджет законнары нигезендә әзерләргә һәм раслауга кертергә.

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматлар рәсми порталында һәм (http://saby.tatarstan.ru) адресы буенча Саба муниципаль районы рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Саба муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе М.Р.Ишниязовка йөкләргә.

Саба муниципаль
районы башлыгы Р.Н. Минниханов